ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2021 г. Заинск № 189

**«Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмнәрен раслау турында»**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнарның кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:
1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:
- ялгыз яшәүче граждан өчен – 28 755,58 сум;
- 2 кешедән торган гаилә өчен – 18 299,0 сум;
- өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 15 684,86 сум.
1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган, салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь бәясе күләме:
- ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 103 780,37 сум;
- 2 кешедән торган гаилә өчен -1 404 811,38 сум;
- 3 кешедән торган гаилә өчен - 1 806 186,06 сум;
- 4 кешедән торган гаилә өчен - 2 408 248,08 сум;
- 5 кешедән торган гаилә өчен - 3 010 310,10 сум;
- 6 кешедән торган гаилә өчен - 3 612 372,12 сум;
- 7 кешедән торган гаилә өчен - 4 214 434,14 сум;
- 8 кешедән торган гаилә өчен - 4 816 496,16 сум;

- 9 кешедән торган гаилә өчен - 5 418 558,18 сум;
- 10 кешедән торган гаилә өчен - 6 020 620,20 сум;

2. «Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмнәрен раслау турында» 2020 елның 01 июлендәге 278 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Уртак торак-көнкүреш комиссиясенә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1, 1.2 пунктлары күрсәткечләре белән файдаланырга.

4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист